КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 декабрь г.Казань № 1141

«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын үтәү өчен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторларына:

Татарстан Республикасы бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр керүне тәэмин итү, шулай ук аларны түләү өчен бурычларны киметү буенча чаралар күрергә;

квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән вакытларда һәм форма нигезендә керемнәрнең ай саен керү фаразларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертергә;

квартал саен керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы аналитика материалларын, керемнәр буенча бюджетның фактагы үтәлешенең фараздан тайпылу сәбәпләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән вакытларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертергә;

аларның ведомство буйсынуындагы бюджет керемнәре администраторлары исемлекләрен билгеләү турында норматив хокукый актлар кабул итүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәренең тиешле бюджет классификациясе кодларына күчерү максаты белән ачыкланмаган керүләрне кичектергесез рәвештә тәгаенләүне гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын формалаштыру һәм алып бару өчен кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән раслаган тәртиптә һәм вакытларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының вәкаләтләре һәм (яки) алар тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре составы үзгәргән очракта, вәкаләтләренә һәм (яки) идарә ителә торган керемнәр составына үзгәреш кертелә торган закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә үзгәрешләр кертелү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына мәгълүмат кертергә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән вакытларда һәм форма нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын эчке һәм тышкы финанслау чыганаклары акчасын ай саен җәлеп итү һәм каплау фаразларын элегрәк бирелгән бюджет кредитларын каплауга күздә тотылган акчаны кире кайтару суммаларын исәпкә алып кертергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына җирле бюджетларның үтәлеше турындагы мәгълүматны, бу карарның 2 нче пунктындагы өченче, дүртенче һәм җиденче абзацлары һәм 3 нче пункты белән күздә тотылган шундый ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

5. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2020 елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына һәм җирле бюджетларга субвенцияләр, субсидияләр, максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлешләре (Россия Федерациясе Президентының резерв фонды бюджет ассигнованиеләре финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган бюджетара трансфертлардан тыш) Татарстан Республикасы бюджетына 2020 елның беренче 15 эш көне эчендә кире кайтарылырга тиеш дип;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән 2019 елда файдаланылмаган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу (булмау) турында карар кабул итү һәм алар тарафыннан 2020 елда аларны шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булу турындагы карар кабул ителгән әлеге бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына һәм җирле бюджетларга кире кайтару, Татарстан Республикасы бюджетына әлеге акча кергән көннән 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, бюджет акчасының баш администраторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә формалаштырылган тиешле бюджет чыгымнары турындагы хисапны карап тикшерү нәтиҗәләреннән чыгып гамәлгә ашырыла дип;

бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакытны үтәү максатларында,

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре белән бюджетара трансфертларны кире кайтарудан идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды идарәсе органы, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан бу пунктның өченче абзацы белән күздә тотып кертелгән хисапларны карап тикшерүне һәм субвенцияләр, субсидияләр һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән һәм 2019 елда файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар өлешләрен 2020 елда шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булу турындагы карарны әлеге акча Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килештерүгә җибәрүне тәэмин итә дип;

2019 елда бирелгән һәм максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертларның калган өлешенә ихтыяҗ булу турында карарлар әлеге калган өлештән артмаган күләмдә түбәндәге очракларда кабул ителә дип:

Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан кабул ителгән, бюджетара трансфертларның калган өлеше аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торучы үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре булганда,

әгәр дә 2020 елда җирле бюджетка Татарстан Республикасы бюджетыннан файдаланылмаган бюджетара трансфертларны биргәндә элегрәк билгеләнгән максатларга туры килә торган максатлар өчен бюджетара трансфертлар бирү каралмаган һәм муниципаль район, шәһәр округы бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып бюджетара трансфертларның калган өлеше торган акчасын алучы тарафыннан кабул ителгән һәм үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре булса;

дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләр 2020 елның 1 февраленә кадәр түбәндәге субсидияләрнең калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә дип:

аларга 2019 елда дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бирелгән, дәүләт йөкләмәсе белән билгеләнгән һәм ирешелмәгән күрсәткечләргә туры килә торган. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр дәүләт йөкләмәләрен үтәү турындагы хисаплар нигезендә әлеге акчаны кире кайтаруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә бирелгән, аларга карата 2020 елда шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булу Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланмаган;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр тарафыннан федераль башкарма хакимият органнарына кертелә торган бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисаплар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелергә тиеш дип;

социаль-мәдәни өлкә һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларын дәүләт милкеннән муниципаль милеккә тапшыру, агымдагы елда тапшырылган объектларның эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү чыганагын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының күчерү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр үзләре кабул иткән карарлар нигезендә 2020 елда Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшыра торган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар исемлеген расларга.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

2020 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елда чыгымнар буенча Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә җибәрелгән норматив хокукый актлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларга план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә туры китерүне тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт заказчыларына, шул исәптән дәүләт казна учреждениеләренә 2020 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2019 елда түләнергә тиешле әлеге дәүләт контрактларына түләү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре өлешләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына мәгълүмат кертергә.

9. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2021 елның 1 гыйварына кадәр түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

хезмәт өчен түләү буенча бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән тәртиптә расланган лимитларын башка максатларга күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитларын (хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне түләүгә бюджет йөкләмәләре лимитларыннан тыш) киметү хисабына арттыру (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләрен эштән азат иткәндә түләүләрне гамәлгә ашыру максатларында бюджет йөкләмәләре лимитларын арттырудан тыш);

хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне түләүгә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларын башка максатларга күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитларын (хезмәт өчен түләү буенча бюджет йөкләмәләре лимитларыннан тыш) киметү хисабына арттыру (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары хезмәткәрләрен эштән азат иткәндә түләүләргә исәпләүләрне түләү максатларында бюджет йөкләмәләре лимитларын арттырудан тыш);

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча конкурста, аукционда катнашуга заявкаларны тәэмин итү сыйфатында торгларда катнашучылар тарафыннан кертелә торган акча суммалары, Татарстан Республикасы исеменнән

төзелгән дәүләт контрактларының үтәлешен тәэмин итү сыйфатында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашучылар тарафыннан кертелә торган акча Татарстан Республикасы учреждениеләренең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында учреждениеләр белән вакытлыча эш итү максатында керә торган акча белән операцияләрне исәпкә алу өчен алар тарафыннан ачылган шәхси исәпләрендә исәпкә алына;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр (дәүләт контрактлары) төзегәндә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар аларга билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түбәндәге аванс түләүләрен күздә тотарга хокуклы:

шартнамәнең (контрактның) 100 процент суммасына кадәр булган күләмдә – матбугат басмаларына язылу һәм аларны сатып алу турындагы, элемтә, кабель һәм спутник телевидение хезмәтләре күрсәтү турындагы, ягулык-майлау материаллары, транспорт чаралары, юлламалар, авиация, тимер юл, шәһәр һәм шәһәр яны транспорты белән юл йөрү өчен билетлар, ашыгыч ярдәм күрсәтү билгеләнешендәге медикаментлар (кеше тормышына куркыныч янаганда кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү өчен таләп ителә торган медикаментлар) сатып алу турындагы, квалификация күтәрү курсларында уку турындагы, һөнәри яңадан әзерләү үтү турындагы, фәнни, методик, фәнни-гамәли һәм башка конференцияләрдә катнашу турындагы, проект документларына һәм инженерлык эзләнүләренә дәүләт экспертизасы үткәрү турындагы, капиталь төзелеш объектларының, реконструкция яки техник яңадан җиһазландыру смета кыйммәтен билгеләү дөреслегенә тикшерү үткәрү турындагы шартнамәләр (контрактлар) буенча, транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан чит ил оешмалары белән төзелә торган Россия Федерациясе гражданнарына Россия Федерациясе территориясеннән читтә дәвалау үткәрү, мәгълүмати тәэмин итү турындагы, йөртүләр (ташулар) хезмәтләре өчен түләүгә шартнамәләр буенча, фәнни, мәдәни, экскурсия һәм спорт чараларын үткәрүгә шартнамәләр буенча, янгын сүндерү чараларын үткәрү турындагы шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча,

шартнамәнең (контрактның) 30 процент суммасыннан артмаган, әмма иң күбе бюджет йөкләмәләренең ирештерелгән лимитлары күләмендә – әгәр дә Россия Федерациясе законнары белән башкасы күздә тотылмаса, калган шартнамәләр (контрактлар) буенча;

юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) (алга таба – юридик затлар), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәт күрсәтүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү 2020 елда Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язуында билгеләнгән күләмдә бюджет ассигнованиеләрен һәм

бюджет йөкләмәләре лимитларын ирештерү турында хәбәрнамәләр җиткерергә;

2020 елның 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары шартлары нигезендә әлеге 2019 елда түләнергә тиешле контрактларга түләү өчен бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасы чикләрендә булган, 2020 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Россия Федерациясенең сатып алулар өлкәсендәге контракт системасы турындагы законнары нигезендә төзелгән контракт (шартнамә) булганда, муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә сарыф ителә торган субсидияләрне, башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләргә түбәндәгеләр өчен күчерүне гамәлгә ашырырга:

контракт (шартнамә) белән билгеләнгән күләмдә аванс түләү өчен;

эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне, товар кайтартуны раслый торган документлар булганда контракт (шартнамә) буенча башкарылган эшләргә, күрсәтелгән хезмәтләргә, кайтартылган товарга түләү өчен.

11. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә:

үзләренә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм җыелма бюджет исемлегенең расланган күрсәткечләре нигезендә бюджет йөкләмәләре лимитларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән ведомство буйсынуындагы эш итүчеләр һәм (яки) аны алучылар арасында бүләргә;

максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертлар биргәндә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә бюджетлар арасындагы исәп-хисаплар буенча хәбәрнамәләрне җиткерергә.

12. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары гамәле 2020 елга озайтыла;

бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының аерым нормалары гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр туктатып торыла.

13. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының күчерү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр үзләре кабул иткән карарлар нигезендә 2020 елда Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшыра торган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар
исемлеге

| Бюджетара трансферт исеме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүченең исеме |
|---|---|
| Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе |
| Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның антлы утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (аңа үзгәреш кертү) буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Россия Федерациясе субъектларының дәүләт (муниципаль) милке объектларына капитал салуларны финанслашу өчен һәм (яки) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт (муниципаль) милкендәге объектларына капитал салуларга карамый торган чараларны финанслашу өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Мәдәният өлкәсенә ярдәм күрсәтү өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Халкы 300 мең кешегә кадәр булган торак пунктлардагы муниципаль театрларның иҗат эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү һ матди-техник база- | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |

| Бюджетара трансферт исеме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүченең исеме |
|---|---|
| сын ныгыту өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | |
| Модельле муниципаль китапханәләр булдыру өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары тормышка ашыру өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| Авыл территорияләрен комплекслы үстерү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| «2016 – 2020 елларга Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү» федераль максатчан программасын тормышка ашыру өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче
карарына 1 нче кушымта

Гамәле 2020 елга озайтыла торган
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары
исемлеге

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары:

«2005 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан социаль ярдәмнең аерым чараларын тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчаны тоту тәртибен раслау турында» 2005 ел, 21 март, 140 нчы;

«2006 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидияләргә бүлеп бирелә торган акчаны тоту тәртибен раслау турында» 2006 ел, 16 февраль, 55 нче;

«Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендәге һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә керә торган архив документларын саклау, комплектлау, исәпкә алу һәм файдалану буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 2008 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2008 ел, 21 май, 329 нчы;

«Хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны 2008 елда сарыф итү кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 7 июль, 478 нче;

«Дарулар белән тәэмин итү өлкәсендәге аерым вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында 2010 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 923 нче;

«2010 елда Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджетында җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез файдалануны тәэмин итү өчен каралган субсидияләрне һәм субвенцияләрне бирү турында» 2009 ел, 10 март, 134 нче;

«Кирәкле дару чаралары, медицина әһәмиятендәге әйберләр, шулай ук инвалид балалар өчен дәвалану туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итү өлешендә түләүсез өстәмә медицина ярдәме күрсәтү буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәт күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 20 апрель, 246 нчы;

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды турында» 2007 ел, 21 июль, ФЗ-185 нче Федераль закон кысаларында 2011 елда гражданнарны җимерек торак фондтан күчерү өчен субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 27 май, 427 нче.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче
карарына 2 нче кушымта

Гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр туктатыла торган, финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының аерым нормалары
исемлеге

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Радиоактив матдәләр һәм радиоактив калдыкларның исәбен алу һәм аларны тикшерүдә тоту буенча региональ мәгълүмат-анализ үзәген төзү турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 556 нчы карарының 4 нче пункты.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрне социаль-икътисадый үстерүне һәм җәмәгать финанслары белән сыйфатлы идарә итүне стимуллаштыру фондыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә дотацияләр бирү тәртибе турында» 2007 ел, 16 июль, 303 нче карары.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Химиклар көнен бәйрәм итү турында» 2011 ел, 15 июнь, 481 нче карарының 3 нче пункты.

4. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадый әһәмияткә ия булган төбәк программаларын раслау турында» 2011 ел, 25 июль, 580 нче карары.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күмү урыннарын карап тоту чыгымнарын финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 18 ноябрь, 946 нчы карарының 3 нче пункты.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекле янгын сүндерүчеләргә, янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә һәм аларның гаиләләре әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау чаралары турында» 2012 ел, 10 август, 694 нче карары.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында товарлы аквакультураны (товарлы балыкчылыкны) үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 28 декабрь, 991 нче карары.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарының 1 нче пунктындагы егерме дүртенче һәм егерме алтынчы абзацлары.

___